МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2022 г.Казань № 136

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 23 мартында 8984 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.10.2018 №950, 07.05.2019 №331, 16.11.2019 №1037, 10.02.2020 №82, 22.06.2020 №449, 02.10.2020 №695, 04.06.2021 №396 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт

учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
«_28_» __02__2022 №_136_
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.7 пунктның 2 пунктчасында:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал)»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү чорлары һәм тәртибе турында мәгълүмат алу мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;»;

1.9 пунктының җиденче абзацында:

«(210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1, 2 пунктлары)» сүзләрен «, 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьсының 3 пункты нигезендә бирелгән.» сүзләренә алмаштырырга;

«Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затның шәхси эше бланклары үрнәкләрен раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык (алга таба – 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык).» сүзләрен «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның үрнәкләрен раслау турында» 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык (алга таба – 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык).» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда тулы күләмдә булышлык күрсәтү

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы

Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

эшсез гражданинга 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 6 нчы кушымтадагы үрнәк буенча башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү;

эшсез гражданинга башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирүдән баш тарту турында карар;

эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә яисә эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашуда финанс ярдәме күрсәтү турында карар;

эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә яисә эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашуда финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе эшсез гражданинга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кәгазь чыганакта бирелә яисә электрон почта адресы буенча почта юлламасы итеп җибәрелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне

туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты 30 минуттан артмаска тиеш, эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүгә ярдәм итү турында шартнамә (алга таба – күченү турында шартнамә) яки эшкә урнашу өчен башка җиргә күченеп урнашуга ярдәм итү турында шартнамә (алга таба – күченеп урнашу турында шартнамә) төзү өчен кирәк булган вакыттан тыш, шулай ук эшсез гражданинга (эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына) финанс ярдәме күләмен билгеләү һәм аны банк яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счетка (исәп-хисап счетына) күчерү вакытыннан тыш.

Инвалидлар категориясенә керүче эшсез гражданиннарга, инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча хосусый программаны (алга таба – хосусый программа) яки хосусый программадан федераль медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән өземтә (инвалидлар категориясенә карый торган эшсез гражданнар өчен) шәхси инициатива белән тапшырылмаган очракта, һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гаризаны теркәгән көннән башлап җиде эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Күченү яисә күченеп урнашу турында шартнамә төзелгән эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән башлап 10 календарь көннән соңга калмыйча кабул ителә.

2.4.3. Эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләнгән очракта, финанс чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җиргә күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 15 июнендәге 515 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җиргә күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү тәртибе (алга таба – 515 номерлы Тәртип) һәм төзелгән шартнамә нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көннән башлап календарь көннәрендә исәпләнә торган җиде көнлек чорда эшсез гражданин тарафыннан күрсәтелгән шәхси счетка (исәп-хисап счетына) күчерелә.

2.4.4. Эшсез гражданин белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын килештерү телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла. Мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килештерелгән очракта, эшсез гражданин тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Эшсез гражданин күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру күпфункцияле үзәк белән халыкның

мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү (җибәрү) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көннән алып бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе эшсез гражданин мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булып 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 11 нче кушымта нигезендәге үрнәк буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) яки 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 12 нче кушымта нигезендәге үрнәк буенча халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме) һәм дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән ризалыгы тора.

2.5.2. Эшсез гражданин мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны) күрсәтә.

2.5.3. Гаилә әгъзалары булган эшсез гражданин эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм буенча дәүләт хезмәтен алу өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

үзенең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, - чит ил гражданины булган гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, - гражданлыгы булмаган зат булып торучы гаилә әгъзасы өчен) билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе, эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзалары тууы турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклыкларның күчермәләре һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;

эшсез гражданинның гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

эшсез гражданинның персональ белешмәләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырганда алар исеменнән эш йөртүгә вәкаләтле булуын.

Документларның күчермәләре, әгәр алар билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана.

Эшсез гражданин, шул исәптән түбәндәге документларны да тапшыра:

эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзалары тууын дәүләт теркәвенә алу турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклык (алга таба – туу турында таныклык) һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклык (алга таба – өйләнешү турында таныклык) һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе.

2.5.4. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан финанс ярдәмен билгеләү һәм халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә вакытлыча эшкә урнашу өчен күченгәндә (яңа яшәү урынына күченеп урнашканда) эшсез гражданинга күчерү турында карарны кабул итү өчен эшсез гражданин 515 номерлы тәртипкә 1-4 нче кушымталарга туры китерелгән форма буенча гариза тапшыра, түбәндәге документларны теркәп:

вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә:

эш бирүче белән төзелгән, эш бирүче тарафыннан расланган хезмәт килешүе күчермәсен;

эш бирүче тарафыннан тиешенчә таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчерәсе (оригинал тапшырылмый торган очракта) һәм (яки) әлеге эш бирүчедә хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорга):

- 515 номерлы Тәртипнең 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктларында каралган транспорт һәм тәүлек чыгымнарын өлешчә компенсацияләү очрагында кабул итү датасын һәм эш урынын күрсәтеп;

- эш урынын күрсәтеп, хезмәт килешүенең яки күчену турындагы килешүнең вакыты бетүгә бәйле рәвештә эштән җибәрү турындагы язу белән, – компенсациянең бер өлеше алдарак алынган очракта;

- 515 номерлы Тәртипнең 2.1.2 пунктында каралган финанс ярдәме алуга гариза элегрәк бирелмәгән булса, күчену турындагы килешүнең гамәлдә булу чоры беткәч эшкә алу датасын, эш урынын, эштән китү датасын һәм эштән китү нигезләрен күрсәтеп;

515 номерлы тәртипнең 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктларында каралган чыгымнар турындагы белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең әлеге пунктларында каралган чыгымнарны компенсацияләү очрагында);

515 номерлы тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 пункты нигезендә элегрәк өлешчә компенсацияләү очрагында);

515 номерлы тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515

номерлы Тәртипнең 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктлары нигезендә элегрәк компенсация гамәлгә ашырылмаган очракта);

банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетны (исәп-хисап счетын) күрсәтеп, документ күчермәсен;

эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашканда:

эш бирүче белән төзелгән, эш бирүче тарафыннан расланган хезмәт килешүе күчермәсен;

эш бирүче тарафыннан тиешенчә расланган хезмәт кенәгәсенең (төп нөсхәсе куелмаган очракта) күчермәсе һәм (яки) хезмәткәрнең әлеге эш бирүчедә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, эшкә алу датасын һәм эш урынын күрсәтеп (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чор өчен):

эшсез гражданинның һәм аның гаилә әгъзаларының күченеп урнашу буенча транспорт чыгымнары, яңа яшәү урынына барган вакытта тәүлеклек чыгымнары һәм элеккеге яшәү урыныннан яңа яшәү урынына йорт мөлкәтен алып бару бәясен түләү чыгымнары (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, исәп-хисап-фактуралары, квитанцияләр, касса чеклары һ.б.) турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләре;

эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсен;

эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, - чит ил гражданины булган гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, - гражданлыгы булмаган зат булып торучы гаилә әгъзасы өчен) билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен;

гаилә әгъзаларының персональ белешмәләрен тапшырганда эшсез гражданинның гаилә әгъзалары исеменнән яки аларның законлы вәкилләре исеменнән эш итүгә вәкаләтле булуын раслаучы документны;

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетны (исәп-хисап счетын) күрсәтеп, документ күчермәсен.

2.5.6. Гариза эшсез гражданинның шәхси яки «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре, паспорт күчермәсен яисә аны алмаштыра торган документ күчермәсен дә кертеп, билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза кәгазен эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.7. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар эшсез гражданин тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә эшсез гражданин исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

почта аша.

Гариза белән аңа теркәлә торган документлар шулай ук эшсез гражданин тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр алар билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана.

## 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

-эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алучы ашыруга вәкаләтле оешмаларда);

гражданинның әлеге эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорга) (ТР Пенсия фондында);

хосусый программадан өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);

организмының бозылган үзлекләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр.

Әлеге белешмәләр, аларны медик-социаль экспертиза федераль учреждениесе җибәрмәгән очракта, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы теркнәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгының 1 нче кушымтасындагы 14 пунктының «д» пунктчасы нигезендә мөстәкыйль соратып алына.

2.6.2. Эшсез гражданин әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

Эшсез гражданин тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Бу пунктта күрсәтелгән документлар эшсез гражданин тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

2.6.3. Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

2.6.4. Эшсез гражданиннан түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ санлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүгә ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документлар белән әлеге Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

түбәндәгеләрнең булмавы:

- эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасы һәм халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән ризалыгы булмау;

- Россия Федерациясе гражданины паспортының яки аны алмаштыра торган документның (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документларның (чит ил гражданнары өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документларның (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

- инвалидның хосусый тернәкләндерү программасы яисә инвалидның билгеләнгән тәртиптә бирелә торган хосусый тернәкләндерү яисә абилитацияләү программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);

почта аша алынган гаризага теркәлгән документларның билгеләнгән тәртиптә таныклап тапшырылмавы.

2.8.3. Халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүеп урнашуда ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документлар белән әлеге Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

түбәндәгеләрнең булмавы:

- эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасы һәм халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән ризалыгы булмау;

- Россия Федерациясе гражданины паспортының яки аны алмаштыра торган документның (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документларның (чит ил гражданнары өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документларның (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

- инвалидның хосусый тернәкләндерү программасы яисә инвалидның билгеләнгән тәртиптә бирелә торган хосусый тернәкләндерү һәм абилитацияләү программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);

- эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар (чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар, – мөрәҗәгать итүченең чит ил гражданины булып торган гаилә әгъзасы өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, – мөрәҗәгать итүченең гражданлыгы булмаган гаилә әгъзасы өчен;

почта аша алынган гаризага теркәлгән документларның билгеләнгән тәртиптә таныклап тапшырылмавы.

2.8.4. Күченү турында шартнамә яки күченеп урнашу турында шартнамә төзелгән эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

дөрес булмаган мәгълүмат бирү;

башка җирлеккә яңа яшәү урыны буенча күченеп урнашканда яңа эш урыны буенча теркәлү булмавы;

төзелгән хезмәт килешүе нигезендә хезмәткәрнең эшкә керешүдән баш тартуы;
документларны тапшырмау яки документларны тулы булмаган күләмдә тапшыру.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта чират көтүнең иң күп вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

### 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә дә

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза гариза кергән көннән башлап бер көн эчендә теркәлә.

Гаризаны теркәү дигәндә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның (физик затлар һәм эш бирүчеләрнең) электрон регистрына (алга таба – Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистры) эшсез гражданин тарафыннан тапшырылган документларда булган белешмәләрне исәпкә алуның теркәү номерын беркетеп кертү турында сүз бара.

2.13.2. Эшсез гражданинның таләбе буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

2.13.3. Гаризаны электрон формада җибәргән очракта, эшсез гражданин гариза җибәрелгән көнне электрон почта аша гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаны теркәү номеры һәм бирү көне күрсәтелгән була.

2.13.4. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Административ регламентның 1.7 пунктының 2 пунктчасының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

гариплеге булган затка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

гариплеге булган затларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны,

тамгаларны һәм язулы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм капма-каршы фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н санлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү.

2.14.3. Гариплеге булган затларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген тудыру өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

гариплеге булган затларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

ишетү буенча гариплеге булган затларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

гариплеге булган затларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.4. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

эшсез гражданин өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын

кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

эшсез гражданин өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Административ регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Административ регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.15.3. Эшсез гражданинның халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ рәвешендә – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә эшсез гражданинның мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.4. Күпфункцияле үзәктә, КФҮ ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

Эшсез гражданин күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза КФҮ теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле

үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эшсез гражданнарга телефон яки видеоэлемтә аша, «Интернет» челтәрен кулланып эш бирүче белән әңгәмәләр үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны эшсез гражданин Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы порталында алырга мөмкин.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 2.16. Экстерриториаль тәртип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль тәртиптә күрсәтелгән очракта) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүдән тыш, электрон формада күрсәтелми.

Үзләре турында белешмәләр Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган эшсез гражданнарга телефон яки электрон элемтә чараларын кулланып, эшсез гражданинның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе эш бирүченең хезмәт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләренә туры килүе шарты белән, өч көн эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә килү тәкъдиме белән, эш бирүчедән буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында белешмәләр килүе хакында мәгълүмат алу мөмкинлеге бирелә.

2.16.2. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар мәшгульлек үзәге бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, эшсез гражданин тарафыннан мәшгульлек үзәгенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

Гариза һәм эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.

2.16.3. Документларны (документларның күчермәләрен) электрон документлар формасында тапшырган очракта, әгәр алар 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) булса, финанс ярдәмен билгеләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларның төп нөсхәләре

яки законнарда билгеләнгән тәртиптә кәгазьдә таныкланган күчермәләре халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылганнан соң гамәлгә ашырыла.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу өчен башка урынга күченүдә ярдәм итү (алга таба – эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүдә ярдәм итү);

эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм итү (алга таба – эшкә урнашу өчен башка җиргә күченеп урнашуда ярдәм итү).

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.2.1. Вакытлыча эшкә урнашу өчен эшсез гражданинга башка урынга күченүгә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

эшсез гражданинга консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган мәгълүматларны анализлау;

эшсез гражданинга түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

- башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булуы турында;

- эшнең характеры, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә карата белдерелә торган квалификация таләпләре, әлеге оешмаларның хезмәткәрләренә белдерелә торган ташламалар турында;

- башка җирлектә эш урыны буенча торак белән тәэмин итү мөмкинлекләре турында;

- халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга белдерелә торган финанс ярдәме күләмнәре, аны бирү һәм кире кайтару тәртибе һәм шартлары турында;

башка җирлектә эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрыннан өземтә бирү;

эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү;

эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү;

эшсез гражданинга башка җирдә эшкә урнашу өчен юллама бирү;

эшсез гражданин белән күченү турында шартнамә төзү;

күченү турында шартнамә төзелгән эшсез гражданинга күченгәндә финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү һәм финанс ярдәмен билгеләү;

эшсез гражданинга финанс ярдәмен күчерү;

Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр кертү.

3.2.2. Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына башка җирлеккә күченеп урнашуда ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

эшсез гражданинга консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган мәгълүматларны анализлау;

мәгълүмат алу өчен ведомствоара гаризалар формалаштыру;

эшсез гражданинга түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

- башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булуы турында;

- эшнең характеры, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә карата билгеләнә торган квалификация таләпләре, әлеге оешмаларның хезмәткәрләренә билгеләнә торган ташламалар турында;

- башка җирлектә эш урыны буенча торак белән тәэмин итү мөмкинлекләре турында;

- эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына эшкә урнашу өчен башка җиргә күчеп урнашканда бирелә торган финанс ярдәме күләмнәре, аны бирү һәм кире кайтару тәртибе һәм шартлары турында;

башка җирлектә эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрыннан өземтә бирү;

эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү;

эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү;

эшсез гражданинга башка җирдә эшкә урнашу өчен юллама бирү;

эшсез гражданин белән күченеп урнашу турында шартнамә төзү;

күченеп урнашу турында шартнамә төзелгән эшсез гражданинга күченеп урнашканда финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү һәм финанс ярдәмен билгеләү;

эшсез гражданинга кредит оешмасында аның тарафыннан ачылган шәхси счетка финанс ярдәмен күчерү.

3.2.3. Эшсез гражданинга дәүләт хезмәтен электрон формада, КФҮ аша, КФҮ еррактагы эш урыны аша күрсәтү.

3.2.4. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.3. Вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Административ регламентта каралган административ гамәлләрне үтәү

3.3.1. Эшсез гражданинга консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

Эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итүе яки мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү

турындагы тәкъдим белән ризалашуы административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен эшсез гражданин (шәхсән яки телефон аша) яисә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итә.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражанинны консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм эшсез гражданинга ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әгәр эшсез гражданин мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга тели икән, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, язмача консультация бирә.

Үтәү вакыты: процедура эшсез гражданин мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3.2. Эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган мәгълүматларны анализлау.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза алынуы яисә эшсез гражданинның әлеге җирлектә вакансия булмаганда эшсез гражданин буларак яңадан теркәлү максатларында халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән көнендә халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риазалашуы административ гамәлне башкару өчен нигез булып тора.

Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгы белән расланган үрнәк (11 нче кушымта) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны алынган көнендә кабул итә һәм терки. Кирәк булганда, эшсез гражданинга гариза тутыруда ярдәм итә.

Эшсез гражданинның гаризасы халыкның мәшгульлек үзәгенә язма рәвештә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә килгән очракта яисә КФҮ, ерактагы эш урыны аша тапшырылганда, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көннән башлап киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гражданин белән аны шәхсән кабул итү көнен, вакытын килештерә. Эшсез гражданин белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын килештерү телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Шәхси кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

әлеге Административ регламентның 2.5. пунктының 2.5.2 пунктчасында каралган документ булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат турындагы белешмәләрне эзләтү билгеләрен Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

эшсез гражданинның эшсез гражданин буларак халыкның мәшгульлек үзәгендә торамы-юкмы икәнлеген, эшсез гражданинның инвалидлар категориясенә керәме-юкмы икәнлеген ачыклый (халыкның мәшгульлек үзәгеннән тәкъдим булган һәм эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булган очраклардан тыш);

халыкның мәшгульлек үзәгенең хәзерге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен (булган очракта) ала.

Инвалидлар категориясенә карый торган эшсез гражданин МСЭ федераль учреждениесе тарафыннан бирелгән хосусый программаны үз инициативасы белән тапшырмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкның мәшгульлек үзәкләре һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык нигезендә, организмының бозылган функцияләрен һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен электрон рәвештә белешмәләр ала.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2 пунктчасында һәм 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтадагы үрнәк буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны кул куйдыртып, аның белән таныштыра, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә бирә.

Әгәр эшсез гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән имзалатып таныштырылмаган булса, аның адресына дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында язма белдерү җибәрелә.

Баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләвен дәвам итә.

Процедураларны үтәү вакыты:

әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән мизгелдән башлап 10 минуттан артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса яисә эшсез гражданин инвалидлар категориясенә караса һәм аның тарафыннан үз инициативасы белән хосусый программа тапшырылган булса яисә халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булган очракта;

инвалидлар категориясенә карый торган эшсез гражданин үз ихтыяры белән хосусый программаны тапшырмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә

хосусый программадан өземтә булмаган очракта, әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән мизгелдән башлап җиде эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза, электрон рәвештә алынган белешмәләр, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме).

Халыкның мәшгульлек үзәгенең эшсез гражданнарның теркәү исәбен алып бара торган белгече, эшсез гражданин туры килә торган эш сайлауда халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән очракта:

әлеге Административ регламентның 2.5. пунктының 2.5.2 пунктчасында каралган документ булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат турындагы белешмәләрне эзләтү билгеләрен Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

халыкның мәшгульлек үзәгенең хәзерге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен (булган очракта) ала;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тәкъдим итә һәм эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне рәсмиләштерү юлы белән халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булуын (риза булмавын) 2021 елның 20 октябрендәге 738н номеры боерык белән расланган рәвештә (12 нче кушымта) рәсмиләштерә.

Халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкның мәшгульлек үзәкләре һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык нигезендә, организмның бозылган функцияләрен һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен электрон рәвештә белешмәләр ала.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2 пунктчасында һәм 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасында алтынчы абзацында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтадагы үрнәк буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны кул куйдыртып, аның белән таныштыра, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә бирә.

Баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләвен дәвам итә.

Процедураларны үтәү вакыты:

әлеге пунктта каралган процедуралар эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә туры килә торган эш эзләү өчен килгән вакытта әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2 пунктчасында күрсәтелгән документны күрсәткән мизгелдән башлап 10 минуттан артмаган вакытта гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса яисә эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карап, үз ихтыяры белән хосусый программаны тапшырган булса яисә халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булган очракта;

әлеге пунктта каралган процедуралар эшсез гражданин туры килә торган эш сайлау өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килгәндә әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2 пунктчасында каралган документны күрсәткән мизгелдән башлап җиле эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карап, хосусый программаны үз ихтыяры белән тапшырмаган булса һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән риза булуны (риза булмауны) күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим рәсмиләштерү, белешмәләр бирү турында гариза, электрон рәвештә алынган белешмәләр, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

3.3.3. Эшсез гражданинга вакансияләр булуы (булмавы), финанс ярдәменең күләме, аны бирү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга түбәндәгеләр турында телдән хәбәр итә:

башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булуы турында;

эшнең характеры, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә карата бeлдерелә торган квалификация таләпләре, әлеге оешмаларның хезмәткәрләренә белдерелә торган ташламалар турында;

башка җирлектә эш урыны буенча торак белән тәэмин итү мөмкинлекләре турында;

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга белдерелә торган финанс ярдәме күләмнәре, аны бирү һәм кире кайтару тәртибе һәм шартлары турында.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга вакансияләр булуы (булмавы), финанс ярдәменең күләме, аны бирү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

3.3.4. Башка җирлектә эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрыннан өземтә бирү.

Эшсез гражданинның финанс ярдәме бирү тәртибе һәм шартлары белән риза булуы административ гамәлне үти башлау нигезе булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга, Дәүләт хезмәтләре

күрсәтелә торган затлар регистрында булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, эшсез гражданинның һөнәрен вазыйфасын (белгечлеген), эшчәнлек төрен, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсен, эш тәҗрибәсен һәм күнекмәләрен, соңгы эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләмен, каршы килә торган һәм мөмкинлекле эш төрләре һәм шартлары турындагы киңәшләрне, эзләнә торган эшкә карата эшсез гражданинның теләкләрен (хезмәт хакы, эш вакыты режимы, урнашу урыны, хезмәтнең характеры, вазыйфа, һөнәр (белгечлек)), шулай ук хезмәт функциясен үтәү һәм хезмәткәр кандидатурасына карата таләпләрне исәпкә алып, башка җирлектәге эш вариантларын сайлый.

Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) туры килә торган эш вариантлары булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны эшсез гражданинга тәкъдим итә.

Башка җирлектә эшсез гражданинның теләкләренә туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки һәм эшсез гражданинны, башка җирлектә эш вариантларын эзләү өчен, яңадан халыкның мәшгульлек үзәгенә килергә чакыра.

Эш бирүчедән буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында мәгълүмат алынган очракта, үзе турындагы белешмәләр Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган эшсез гражданинга, эшсез гражданинның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүче таләпләренә туры килү шарты белән, телдән (телефон буенча) яисә язмача (электрон документ рәвешендә) өч көн эчендә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килү турында тәкъдим җиткерелә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлар булган исемлек, яисә халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат чакыру.

3.3.5. Эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан төзелгән буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) исемлеге административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән башка җирлектәге эш вариантын сайлый.

Эшсез гражданин башка җирлектә берничә эш вариантын сайларга хокуклы.

Эшсез гражданин башка җирдә эш вариантын сайламаса, халыкның мәшгульлек үзәге белгече нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданин тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән эш вариантын сайлау яки тәкъдим ителгән эш вариантларыннан баш тарту, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында теркәү.

3.3.6. Эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданин тарафыннан башка җирлектә сайланган эш вариантлары нигезендә телефон яки электрон почта аша эш бирүче белән вакансия булуын һәм, эшкә урнаштыру өчен юллау максатында, эшсез гражданинның кандидатурасын килештерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эшсез гражданинга телефон яки видеоэлемтә аша, «Интернет» челтәрен кулланып әңгәмә үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Эшсез гражданинның кандидатурасын эш бирүче белән килештермәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга әлеге Административ регламентның 3.3.4 - 3.3.5 пунктчаларында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә башка җирдә эш вариантларын сайлауны дәвам итәргә тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү, «Интернет» челтәрен кулланып телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә үткәрү.

3.3.7. Эшсез гражданинга башка җирдә эшкә урнашу өчен юллама бирү.

Эш бирүче белән эшсез гражданинның кандидатурасын килештерү административ гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора.

Эш бирүче белән эшсез гражданинның кандидатурасы килештерелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 6 нчы кушымта нигезендәге үрнәк буенча эшкә юллама рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинга бирә, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү.

3.3.8. Эшсез гражданин белән күченү турында шартнамә төзү.

Күченү турында шартнамә төзү турында карар кабул итү административ гамәлләр башкару өчен нигез булып тора. Күченү турында шартнамәнең бер төр үрнәге Министрлык тарафыннан раслана.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында хәбәр итә һәм эшсез гражданин белән күченү турында шартнамә төзи, ул халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: күченү турында шартнамә төзү.

3.3.9. Күченү турында шартнамә төзелгән эшсез гражданинга күченгәндә финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү һәм финанс ярдәмен билгеләү.

Эшсез гражданиннан башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү

турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документларның булуы административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә электрон документлар рәвешендә җибәрелгән документлар һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләр нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) булырга тиеш.

Гариза әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындагы 2.5.4 пунктчасында каралган документларны теркәп, кулга тапшыру турында белдерү белән почта аша юлланган очракта, финанс ярдәме билгеләү турындагы гаризага эшсез гражданинның шәхесен таныклый торган документның нотариаль таныкланган күчермәсе теркәлә.

Финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул итә. Финанс ярдәме күрсәтү турындагы карар проектын халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентка 7 нче кушымтадагы үрнәк буенча рәсмиләштерә, эшсез гражданинны кул куйдыртып, әлеге карар белән таныштыра һәм имзалау өчен аны халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра.

Финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проектын әлеге Административ регламентның 6 нчы кушымтасындагы үрнәк буенча рәсмиләштерә. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту сәбәпләре, нигезләре, аны бирү тәртибе турында аңлата, эшсез гражданинны кул куйдыртып, әлеге карар белән таныштыра һәм аны, имзалау өчен, халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра.

Әгәр эшсез гражданин финанс ярдәме күрсәтү яки финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән кул куйдыртып таныштырылмаган булса, кабул ителгән карар турында аның адресына язма хәбәр җибәрелә.

Эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданин турында мәгълүматлар эзләтү билгеләрен Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына кертә.

Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентның 8 нче кушымтасы нигезендә башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме билгеләү һәм аның күләмнәре турында боерык проекты әзерли, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра, шулай ук эшсез гражданинны кул куйдыртып, әлеге боерык белән таныштыра.

Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме түләүдән баш тарту турында әлеге Административ регламентның 9 нчы кушымтасындагы үрнәк

буенча боерык проекты әзери, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра, шулай ук эшсез гражданинны, кул куйдыртып, әлеге карар белән таныштыра.

Әгәр эшсез гражданин башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме түләү рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы боерык белән кул куйдыртып таныштырылмаган булса, финанс ярдәме түләүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында аның адресына белдерү җибәрелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына гражданин тарафыннан тапшырылган, әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документларда булган белешмәләрне кертә.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерү, эшсез гражданинны кул куйдыртып, карар белән таныштыру яисә кабул ителгән карар турында эшсез гражданинга язма белдерү җибәрү; эшсез граждинга финанс ярдәме билгеләү турында боерык яисә финанс ярдәме түләүдән баш тарту турында боерык, финанс ярдәме билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында боерык белән эшсез гражданинны кул куйдыртып таныштыру яисә финанс ярдәме билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында эшсез гражданинга язма белдерү җибәрү.

Үтәү вакыты: процедура эшсез гражданиннан гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктындагы 2.5.4 пунктчасында каралган документлар кергән көннән алып 10 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.3.10. Эшсез гражданинга күченгәндә финанс ярдәмен күчерү.

Эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләү турындагы боерык нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге акчалар халыкның мәшгульлек үзәге счетына күчкәннән соң алынган акчаларны эшсез гражданинның шәхси (банк) счетына һәм (яисә) эшсез гражданин тарафыннан 515 номерлы Тәртипнең 1-3 нче кушымталарындагы үрнәк буенча төзелгән гаризада күрсәтелгән башка исәп-хисап счетларына күчерә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече түләү документларындагы белешмәләрне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына кертә.

Үтәү вакыты: процедура халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көннән алып, календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинның шәхси (банк) счетына һәм (яки) эшсез гражданин тарафыннан күрсәтелгән башка исәп-хисап счетына акча күчерү.

3.3.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Эшсез гражданинга 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 6 нчы кушымтадагы үрнәк буенча башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү (бирүдән нигезле рәвештә баш тарту);

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга финанс ярдәмен күрсәтү яисә аны күрсәтүдән дәлилле баш тарту.

3.3.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына административ гамәлләр башкару нәтиҗәләрен кертү.

Административ гамәлне үти башлау өчен мәшгульлек үзәге белгеченең әлеге пунктның 3.3.3-3.3.10 пунктчаларында күрсәтелгән карарларны кабул итүе нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен (әлеге Административ регламентның 3.3.4, 3.3.10, 3.3.10 пунктларында каралган процедураларның берсе тәмамланганнан соң аерым административ гамәлләр башкару нәтиҗәләрен) терки.

Үтәү вакыты: процедура әлеге Административ регламентның 3.3.4, 3.3.7, 3.3.10 пунктларында каралган процедураларның берсе тәмамланганнан соң ике минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында хезмәт күрсәтү (административ гамәлләр башкару) нәтиҗәсен теркәү.

3.4. Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Административ регламентта каралган административ гамәлләрне үтәү.

3.4.1. Эшсез гражданинга консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итүе яки мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән ризалашуы административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен эшсез гражданин (шәхсән яки телефон аша) яисә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итә.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражанинны консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм эшсез гражданинга ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әгәр эшсез гражданин мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга тели икән, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, язмача консультация бирә.

Үтәү вакыты: процедура эшсез гражданин мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.4.2. Эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган мәгълүматларны анализлау.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза алынуы яисә эшсез гражданинның әлеге җирлектә вакансия булмаганда эшсез гражданин буларак яңадан теркәлү максатларында халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән көнендә халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риазалашуы административ гамәлне башкару өчен нигез булып тора.

Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгы белән расланган үрнәк (11 нче кушымта) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны алынган көнендә кабул итә һәм терки. Кирәк булганда, эшсез гражданинга гариза тутыруда ярдәм итә.

Эшсез гражданинның гаризасы халыкның мәшгульлек үзәгенә язма рәвештә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә килгән очракта яисә КФҮ, ерактагы эш урыны аша тапшырылганда, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көннән башлап киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гражданин белән аны шәхсән кабул итү көнен, вакытын килештерә. Эшсез гражданин белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын килештерү телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Шәхси кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

әлеге Административ регламентның 2.5.2, 2.5.3 пунктларында каралган документларның булуын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат турындагы белешмәләрне эзләтү билгеләрен Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрын үз эченә алган программа-техник комплекска кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

эшсез гражданинның эшсез гражданин буларак халыкның мәшгульлек үзәгендә торамы-юкмы икәнлеген, эшсез гражданинның инвалидлар категориясенә керәме-юкмы икәнлеген ачыклый (халыкның мәшгульлек үзәгеннән тәкъдим булган һәм эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булган очраклардан тыш);

халыкның мәшгульлек үзәгенең хәзерге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен (булган очракта) ала;

тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаса, 3.4.3 пунктчасында каралган процедураны гамәлгә ашыра.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2, 2.5.3 пунктчаларында һәм 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтадагы үрнәк буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны кул куйдыртып, аның белән таныштыра, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә бирә.

Әгәр эшсез гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән имзалатып таныштырылмаган булса, аның адресына дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында язма белдерү җибәрелә.

Баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләвен дәвам итә.

Процедураларны үтәү вакыты:

әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән мизгелдән башлап 10 минуттан артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса яисә эшсез гражданин инвалидлар категориясенә караса һәм аның тарафыннан үз инициативасы белән хосусый программа тапшырылган булса яисә халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булган очракта;

инвалидлар категориясенә карый торган эшсез гражданин үз ихтыяры белән хосусый программаны тапшырмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән мизгелдән башлап җиде эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза, электрон рәвештә алынган белешмәләр, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме).

Халыкның мәшгульлек үзәгенең эшсез гражданнарның теркәү исәбен алып бара торган белгече, эшсез гражданин туры килә торган эш сайлауда халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән очракта:

әлеге Административ регламентның 2.5.2, 2.5.3 пунктларында каралган документларның булуын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат турындагы белешмәләрне эзләтү билгеләрен Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрын үз эченә алган программа-техник комплекска кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

халыкның мәшгульлек үзәгенең хәзерге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен (булган очракта) ала;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тәкъдим итә һәм эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне рәсмиләштерү юлы белән халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булуын (риза булмавын) 2021 елның 20 октябрендәге 738н номеры боерык белән расланган рәвештә (12 нче кушымта) рәсмиләштерә;

тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаса, 3.4.3 пунктчасында каралган процедураны гамәлгә ашыра.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2, 2.5.3 пунктчаларында һәм 2.6 пунктында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтадагы үрнәк буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны кул куйдыртып, аның белән таныштыра, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә бирә.

Баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләвен дәвам итә.

Процедураларны үтәү вакыты:

әлеге пунктта каралган процедуралар эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә туры килә торган эш эзләү өчен килгән вакытта әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2, 2.5.3 пунктчаларында күрсәтелгән документларны күрсәткән мизгелдән башлап 10 минуттан артмаган вакытта гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса яисә эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карап, үз ихтыяры белән хосусый программаны тапшырган булса яисә халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булган очракта;

әлеге пунктта каралган процедуралар эшсез гражданин туры килә торган эш сайлау өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килгәндә әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.2, 2.5.3 пунктчаларында каралган документларны күрсәткән мизгелдән башлап җиле эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карап, хосусый программаны үз ихтыяры белән тапшырмаган булса һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән риза булуны (риза булмауны) күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим рәсмиләштерү, белешмәләр бирү турында гариза, электрон рәвештә алынган белешмәләр, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

3.4.3. Мәгълүмат алу өчен ведомствоара гаризалар формалаштыру

Тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә сорала торган белешмәләр белән эш итүче дәүләт органнарына тиешле рәсми мөрәҗәгатьне (рәсми мөрәҗәгатьләрне) җибәрә:

-эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алучы ашыруга вәкаләтле оешмаларда);

гражданинның әлеге эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорга) (ТР Пенсия фондында);

хосусый программадан өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);

организмының бозылган үзлекләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр.

Ведомствоара электрон мөрәҗәгатьне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара мөрәҗәгать (мөрәҗәгатьләр) кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедуралар гариза яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) белешмәләрнең булмавы турында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган белешмәләр.

3.4.4. Эшсез гражданинга вакансияләр булуы (булмавы), финанс ярдәменең күләме, аны бирү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга түбәндәгеләр турында телдән хәбәр итә:

- башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булуы турында;

- эшнең характеры, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә карата белдерелә торган квалификация таләпләре, әлеге оешмаларның хезмәткәрләренә белдерелә торган ташламалар турында;

- башка җирлектә эш урыны буенча торак белән тәэмин итү мөмкинлекләре турында;

- халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен башка җирлеккә күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына бирелә торган финанс ярдәме күләмнәре, аны бирү һәм кире кайтару тәртибе һәм шартлары турында.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч минут

эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга вакансияләр булуы (булмавы), финанс ярдәменең күләме, аны бирү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

3.4.5. Башка җирлектә эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрыннан өземтә бирү.

Эшсез гражданинның финанс ярдәме бирү тәртибе һәм шартлары белән риза булуы административ гамәлне үти башлау нигезе булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга, Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, эшсез гражданинның һөнәрен вазыйфасын (белгечлеген), эшчәнлек төрен, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсен, эш тәҗрибәсен һәм күнекмәләрен, соңгы эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләмен, каршы килә торган һәм мөмкинлекле эш төрләре һәм шартлары турындагы киңәшләрне, эзләнә торган эшкә карата эшсез гражданинның теләкләрен (хезмәт хакы, эш вакыты режимы, урнашу урыны, хезмәтнең характеры, вазыйфа, һөнәр (белгечлек)), шулай ук хезмәт функциясен үтәү һәм хезмәткәр кандидатурасына карата таләпләрне исәпкә алып, башка җирлектәге эш вариантларын сайлый.

Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) туры килә торган эш вариантлары булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны эшсез гражданинга тәкъдим итә.

Башка җирлектә эшсез гражданинның теләкләренә туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки һәм эшсез гражданинны, башка җирлектә эш вариантларын эзләү өчен, яңадан халыкның мәшгульлек үзәгенә килергә чакыра.

Эш бирүчедән буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында мәгълүмат алынган очракта, үзе турындагы белешмәләр Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында булган эшсез гражданинга, һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүче таләпләренә туры килү шарты белән, телдән (телефон буенча) яисә язмача (электрон документ рәвешендә) өч көн эчендә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килү турында тәкъдим җиткерелә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлар булган исемлек, яисә халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат чакыру.

3.4.6. Эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан төзелгән буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) исемлеге административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән башка җирлектәге эш вариантын сайлый. Эшсез гражданин башка

җирлектә берничә эш вариантын сайларга хокуклы.

Эшсез гражданин башка җирдә эш вариантын сайламаса, халыкның мәшгульлек үзәге белгече нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданин тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән эш вариантын сайлау яки тәкъдим ителгән эш вариантларыннан баш тарту, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында теркәү.

3.4.7. Эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү.

Эшсез гражданин тарафыннан тәкъдим ителгән исемлектән эшкә урнашу вариантын сайлау һәм эш бирүчегә юллануга ризалык белдерү административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданин тарафыннан башка җирлектә сайланган эш вариантлары нигезендә телефон яки электрон почта аша эш бирүче белән вакансия булуын һәм, эшкә урнаштыру өчен юллау максатында, эшсез гражданинның кандидатурасын килештерә. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә эшсез гражданинны эшкә урнаштыру мөмкинлеген раслау өчен килештергән көнне эшсез гражданин кандидатурасын күрсәтү турында мәгълүмат җиткерә (киңәш ителә торган рәвеше әлеге Административ регламентның 10 нчы кушымтасында китерелгән).

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эшсез гражданинга телефон яки видеоэлемтә аша, «Интернет» челтәрен кулланып әңгәмә үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Эшсез гражданинның кандидатурасын эш бирүче белән килештермәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга әлеге Административ регламентның 3.4.5 – 3.4.6 пунктчаларында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә башка җирдә эш вариантларын сайлауны дәвам итәргә тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү, «Интернет» челтәрен кулланып телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә үткәрү.

3.4.8. Эшсез гражданинга күченеп урнашканда башка җирдә эшкә урнашу өчен юллама бирү.

Эш бирүче белән эшсез гражданинның кандидатурасын килештерү административ гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора.

Эш бирүче белән эшсез гражданинның кандидатурасы һәм аны эшкә урнаштыру мөмкинлеген килештерелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 6 нчы кушымта нигезендәге үрнәк буенча эшкә юллама рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинга бирә, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга эшкә юллама рәсмиләштерү һәм

бирү.

3.4.9. Эшсез гражданин белән күченеп урнашу турында шартнамә төзү.

Күченеп урнашу турында шартнамә төзү турында карар кабул итү административ гамәлләр башкару өчен нигез булып тора. Күченеп урнашу турында шартнамәнең бер төр үрнәге Министрлык тарафыннан раслана.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга яңа яшәү урыны буенча күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында хәбәр итә һәм эшсез гражданин белән күченеп урнашу турында шартнамә төзи, ул халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: күченеп урнашу турында шартнамә төзү.

3.4.10. Күченеп урнашу турында шартнамә төзелгән эшсез гражданинга күченеп урнашканда финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү һәм финанс ярдәмен билгеләү.

Эшсез гражданиннан башка җирлеккә күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документларның халыкның мәшгульлек үзәгенә алынуы административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Эшсез гражданинга эшкә урнашу өчен юллама биргән халыкның мәшгульлек үзәге, әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган финанс ярдәмен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашуда финанс ярдәм бирү турында карар кабул итә. Финанс ярдәме күрсәтү турындагы карар проектын халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентка 7 нче кушымтадагы үрнәк буенча рәсмиләштерә, эшсез гражданинны кул куйдыртып, әлеге карар белән таныштыра һәм имзалау өчен аны халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра.

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган финанс ярдәмен бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашуда финанс ярдәм бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентның 6 нчы кушымтасы нигезендә эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, финанс ярдәме күрсәтү тәртибен аңлата, эшсез гражданинны әлеге карар белән кул куйдыртып таныштыра, аны, имзалау өчен, халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә имзага тапшыра.

Эшсез гражданин финанс ярдәме күрсәтү яки финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән имзалатып таныштырылмаган очракта, эшсез гражданинга эшкә урнашу өчен юллама биргән халыкның мәшгульлек үзәге аның адресына финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында язма хәбәр җибәрә.

Эшсез гражданин 515 номерлы Тәртипнең 4 нче кушымтасына ярашлы форма

буенча гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документлар белән яңа яшәү урыны буенча (Татарстан Республикасы чикләрендә халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен эшсез гражданинны һәм аның гаилә әгъзаларын башка җирлеккә күчергәндә) халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән очракта һәм гражданин тарафыннан күченү турында килешү күрсәтелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында каралган документларның булуын һәм әлеге Административ регламентның 2.8 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, эшсез гражданинның яңа яшәү урыны буенча халыкның мәшгульлек үзәге белгече документларны күченеп урнашканда башка җирлеккә эшкә урнашу өчен юллама биргән халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә, гариза һәм документлар, шул исәптән почта элемтәсе аша яисә электрон документлар рәвешендә, алынган очракта – гариза һәм документлар халыкның мәшгульлек үзәгенә алынган көнне яисә, гариза һәм документлар халыкның мәшгульлек үзәгенең эш вакыты беткәндә алынган очракта, киләсе көнне. Гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә алынган очракта – халыкның мәшгульлек үзәгенең ял яки эшләми торган бәйрәм көннәреннән соңгы беренче эш көнендә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә электрон документлар рәвешендә җибәрелгән документлар һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләр нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) булырга тиеш.

Гариза әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындагы 2.5.4 пунктчасында каралган документларны теркәп, кулга тапшыру турында белдерү белән почта аша юлланган очракта, финанс ярдәме билгеләү турындагы гаризага эшсез гражданинның шәхесен таныклый торган документның нотариаль таныкланган күчермәсе теркәлә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындагы 2.5.4 пунктчасында каралган документлар тапшырылган очракта, эшсез гражданинның вәкиле эшсез гражданин вәкиленең шәхесен таныклый торган документны, эшсез гражданин исеменнән эш итү хокукына ышанычнамә күрсәтә.

515 номерлы Тәртипкә 4 нче кушымтадагы үрнәк буенча алынган гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында күрсәтелгән документлар (белешмәләр) нигезендә күченеп урнашканда эшкә урнашу өчен юллама биргән халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданин турындагы белешмәләрне эзләтү билгеләрен Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында терки.

Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентның 11 нче кушымтасы нигезендә башка җирлеккә күченеп урнашканда финанс ярдәме билгеләү һәм аның күләмнәре турында боерык проекты әзерли, аны

имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра, шулай ук эшсез гражданинны кул куйдыртып, әлеге боерык белән таныштыра.

Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече башка җирлеккә күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме түләүдән баш тарту турында әлеге Административ регламентның 12 нче кушымтасындагы үрнәк буенча боерык проекты әзери, аны имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә тапшыра, шулай ук эшсез гражданинны, кул куйдыртып, әлеге карар белән таныштыра.

Әгәр эшсез гражданин финанс ярдәме билгеләү, аны бирү чорлары һәм күләмнәре турындагы боерык белән яисә башка җирлеккә күченеп урнашканда финанс ярдәме түләүдән баш тарту турындагы боерык белән имзалатып таныштырылмаган булса, финанс ярдәме билгеләү (аны түләүдән баш тарту) турында аның адресына язма хәбәр җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура эшсез гражданиннан яисә эшсез гражданның яңа яшәү урыны буенча халыкның мәшгульлек үзәгеннән гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2.5.4 пунктчасында каралган документлар алынган көннән алып 10 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерү, эшсез гражданинны кул куйдыртып, карар белән таныштыру яисә кабул ителгән карар турында эшсез гражданинга язма белдерү җибәрү; эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында боерык яисә финанс ярдәме түләүдән баш тарту турында боерык, финанс ярдәме билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында боерык белән эшсез гражданинны кул куйдыртып таныштыру яисә финанс ярдәме билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында эшсез гражданинга язма белдерү җибәрү.

3.4.11. Эшсез гражданинга күченеп урнашканда финанс ярдәмен күчерү.

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме билгеләү турындагы боерык нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге акчалар халыкның мәшгульлек үзәге счетына күчкәннән соң алынган акчаларны эшсез гражданинның 515 номерлы Тәртипнең 4че кушымталарындагы үрнәк буенча төзелгән гаризада күрсәтелгән шәхси (банк) счетына күчерә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече түләү документларындагы белешмәләрне Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына кертә.

Процедураның нәтиҗәсе: акча күчерү.

Үтәү вакыты: процедура халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көннән алып, календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.4.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Эшсез гражданинга 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыкка 6 нчы кушымтадагы үрнәк буенча башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү (бирүдән нигезле рәвештә баш тарту);

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәмен күрсәтү яисә аны күрсәтүдән дәлилле баш тарту.

3.5. Техник хаталарны төзәтү.

Административ процедураны үти башлау өчен эшсез гражданинның техник хатаны төзәтү турында язмача мөрәҗәгате нигез булып тора.

Техник хата мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Административ регламентның 13 нче кушымтасына ярашлы үрнәктә гариза бирелгән очракта төзәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Административ регламентның 14 нче кушымтасы);

- эшкә юлламаны яки эш вариантлары исемлеген, яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдимен үзгәртеп рәсмиләштерә, яисә күченү турындагы шартнамәгә, күченеп урнашу турындагы шартнамәгә өстәмә килешү рәсмиләштерә;

- эшсез гражданинга гаризада күрсәтелгән ысул белән эшкә юлламаны яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдимен үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә күченү турындагы шартнамәгә, күченеп урнашу турындагы шартнамәгә өстәмә килешүне рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән эшкә юллама яки эш вариантлары исемлеге, яисә халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме, яисә күченү турындагы шартнамәгә өстәмә килешү, күченеп урнашу турындагы шартнамәгә өстәмә килешү, әлеге документларны үзгәртеп рәсмиләштерү турында эшсез гражданинга язма хәбәр җибәрү.

3.6. Эшсез гражданин күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны кабул итү һәм теркәү;

Гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрү.

3.6.1. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү

Административ процедураны башкару өчен эшсез гражданинның күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгате нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Үтәү вакыты: әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.6.2. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

Административ процедураны башкару өчен мөрәҗәгать итүченең эшсез гражданнарга һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына халыкның мәшгульлек үзәкләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә күчүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында язма гаризасы һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар бирү нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.6.3. Гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрү.

Әлеге Административ регламентның 3.6.2 пунктчасы нигезендә күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан кабул ителгән һәм теркәлгән гариза административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

КФҮ белгече гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮ эш регламентында, халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

3.7. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү

Административ процедураны үти башлау өчен эшсез гражданин тарафыннан күпфункцияле үзәккә мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә киткән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәгендә бирелгән бәяләмәдәге хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша күпфункцияле үзәккә язмача тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8. Халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү

Административ процедураны үти башлау өчен техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән мөрәҗәгать нигез булып тора.

Күпфункцияле үзәк белгече халыкның мәшгульлек үзәгебелән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.»;

4 бүлекнең 4.2 пунктында «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2021 елның 8 ноябрендәге 972 номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын алып бару тәртибенең» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибен, шул исәптән аларга белешмәләр кертү тәртибен, чорларын һәм белешмәләр рәвешен, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүмат төрләре исемлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 6 нчы бүлеген гамәлдән чыккан дип танырга;

регламентка 5 нче кушымтада «Халыкның мәшгульлек үзәге белгече

________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)»

сүзләрен проектын «Халыкның мәшгульлек үзәгенең карарны әзерләгән белгече»

____________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе ____________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)»

сүзләренә алмаштырырга;

регламентка 6 нчы кушымтада «Халыкның мәшгульлек үзәге белгече

________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)»

сүзләрен проектын «Халыкның мәшгульлек үзәгенең карарны әзерләгән белгече»

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза) »

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе ___________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)»

сүзләренә алмаштырырга;

регламентка 7 нче кушымтада «Халыкның мәшгульлек үзәге белгече

________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)»

сүзләрен «Халыкның мәшгульлек үзәгенең карарны әзерләгән белгече» ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе ________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)»

сүзләренә алмаштырырга.